| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 март 2023ел № 1353

Башкарма комитетның 2021 елның 19 августындагы 5526 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 19 августындагы 5526 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 27 декабрендәге 8482 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы 1217 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктта:

- беренче абзацта «Таможня союзының «Пиротехник эшләнмәләрнең куркынычсызлыгы турында» техник регламенты буенча I класс куркынычка туры килә торган шартлавыклар һәм бенгаль утларыннан тыш» сүзләрен төшереп калдырырга;

- икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- биналарда һәм теләсә нинди функциональ билгеләнештәге корылмаларда, шул исәптән түбәләрдә (түшәмәләрдә), балконнарда, лоджияларда һәм биналар һәм корылмалар фасадларының чыгып торган өлешләрендә, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча өстәмә инженерлык-техник чаралар комплексы эшләнгән махсус сәхнә эффектлары,

техник билгеләнештәге профессиональ пиротехник эшләнмәләр һәм ут эффектлары тудыручы җайланмалар кулланудан тыш;»;

- дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2) 7 пунктның беренче абзацында «I-III класс» сүзләрен «II-III класс» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов